

## 6-7 яшьлек балалар өчен

## уеннар җыентыгы

# “Без уйнарга яратабыз”

**Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы**
**№9 балалар бакчасы тәрбиячесе Хисматуллина Р.Р. төзегән**
**“Без уйнарга яратабыз” дип исемләнгән уеннар җыентыгына**
**рецензия**

Безнең республикада өйрәтү-тәрбия эшен ана телендә оештыру һәм үткәрү мәгариф өлкәсендә дәүләт политикасының мөһим бер принципы булып тора. Татар теленә өйрәтү буенча №9 балалар бакчасы тәрбиячесе Хисматуллина Р.Р. бу принципны тормышка ашыруга зур өлеш кертә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен уен – дөньяны танып белү һәм физик чыныгу чарасы. Уен барышында балаларның иҗади мөмкинлекләре ачыла, мөстәкыйльлекләре үсә, ихтыяр көче формалаша. Шулай ук уеннар балаларның логик фикерләвен, игътибарын, фикер йөртү осталыгын үстерә. 6-7 яшьтәге балалар белән төрле төрдәге уеннар оештыру, уеннар аша максатчан рәвештә сөйләмен үстерү, халык аваз иҗатына кызыксыну уяту, зәвыклык тәрбияләү һәм үстерү, ана телендә әхлак, милли тәрбия алып бару, кечкенә яшьтән балаларның милли үзаңын үстерү әһәмиятле проблемаларның берсе. Әхлак, эстетик, физик тәрбия нигезләре мәктәпкәчә чорда салына һәм алар күпчелек очракта баланың коммуникатив һәм социомәдәни үсешен билгели. Бу аспектлардан караганда татар телендә уеннар җыентыгының эшләнүе аеруча зарури.

“Без уйнарга яратабыз” дип исемләнгән уеннар җыентыгының билгеле бер структурасы бар. Кереш өлештә уеннарның балалар тормышында тоткан урыны ачыклана, әһәмиятлелеге бәян ителә. Эчтәлек балалар белән үткәрелә торган җиде төрле уеннарны үз эченә ала. Алар арасында хәрәкәтле, әйлән-бәйлән, җырлы, дидактик уеннар бар. Автор уеннарны түбәндәге схема буенча күрсәтә: уенның эчтәлеген аңлату, уенның кагыйдәләре белән таныштыру, уен барышы. Тәкъдим ителә торган уеннар кызыклы, мавыктыргыч, 6-7 яшьлек балаларның үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Уеннар җыентыгы зәвыклы итеп бизәлгән.

№9 балалар бакчасы педагогы Хисматуллина Р.Р. төзегән уеннар җыентыгы мәктәпкәчә учреждениеләрендә эшләүче педагоглар, тәрбиячеләр, практика үтүче студентлар өчен гамәли яктан әһәмиятле. Куллануга тәкъдим ителә.

Рецензент:
педагогик фәннәр кандидаты,
З.Т. Шәрәфетдинов ис.
педагогика һәм психология доценты И.Җ. Хәбибуллина

08. 04. 2022 ел

Подпись Хәбибуллиной И.Ж.
ЗАВЕРЯЮ
Начальник канцелярии
Дата 08 апреля 2022

Татарстан республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Әгерҗе шәһәре «9 нчы балалар бакчасы»
муниципаль системасындагы мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе

# 6-7 яшьлек балалар өчен уеннар җыентыгы
## “Без уйнарга яратабыз”

Автор-төзүче:
Хисматуллина Рәзинә Раифовна
югары категорияле татар
теленә өйрәтү буенча тәрбияче

Рецензия язучы:
Хабибуллина Ильсияр Зиганшовна
педагогик фәннәр кандидаты,
З.Т.Шәрәфетдинов ис. педагогика
һәм психология доценты

## ЭЧТӘЛЕК


| I. Максатлар бүлеге (целевой раздел) | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Аңлатма язуы (Пояснительная записка) | 3 |
| 1.2. | Программаны гамәлгә ашыруның максаты һәм бурычлары | 6 |
| 1.3. | Программага хас үзенчәлекләр | 6 |
| 1.4. | Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары | 7 |
| 1.5. | Программаны үзләштерүнең планлаштырылган бурычлары, эчтәлеге, нәтиҗәләре | 8 |
| 1.6 | Төркемнәрнең исемлеге һәм милли составы (кушымтада) | 17 |
| **II. Эчтәлек бүлеге (содержательный раздел)** | | |
| 2.1. | Кечкенәләр төркеме (3-4 яшь) | 18 |
| 2.2. | Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) | 20 |
| 2.3. | Зурлар төркеме (5-6 яшь) | 28 |
| 2.4. | Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) | 41 |
| 2.5. | Үзләштерү дәрәҗәләре планы | 53 |
| 2.6. | Педагоглар, ата-аналар, балаларның уртак эшчәнлеге (кушымтада) | 53 |
| 2.7. | Этно-мәдәни төбәк бердәмлеге (кушымтада) | 53 |
| 2.8 | Коррекцион устерелешле эш (кушымтада) | 53 |
| **III. Оештыру бүлеге (организационный раздел)** | | |
| 3.1. | Предметлы-үстерелешле әйләнә-тирәлек (РППС) (кушымтада) | 56 |
| 3.2. | Материаль яктан тәэмин ителеш (кушымтада) | 57 |
| 3.3. | Программалы-методик яктан тәэмин ителеш (кушымтада) | 57 |
| 3.4. | Циклограмма-эш көне бүленеше (кушымтада) | 57 |
| 3.5. | Белем бирү эшчәнлеге челтәре (кушымтада) | 57 |
| 3.6. | Әдәбият | 57 |